Республика Татарстан
Глава
Какре-Елгинского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Кәкре Елга авыл җирлеге
башлыгы

ул. Советская, д. 22, село Какре-Елга,
Азнакаевский район, 423320

Совет урамы, 22 нче йорт, Кәкре Елга авылы, Азнакай районы, 423320

Тел. (факс) 8(85592) 37-0-47; e-mail: Kelg.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның « 21» ноябреннән № 5

2025 елның 31 октябрендәге 1нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 2025 елның 31 октябрендәге 2 нче номерлы «2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Кәкре Елга торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында» карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәкре Елга торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге Уставы белән карар бирә:

Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Кәкре Елга авылы, Совет ур., 23А йорт адресы буенча урнашкан Кәкре Елга авылы мәдәният йорты бинасында 2025 елның 2 декабренә 10.00 сәгатькә, 2025 елның 31 октябрендәге 1нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 2025 елның 31 октябрендәге 2 нче номерлы «2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Кәкре Елга торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү

турында» карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
Какре Елга торак пунктында теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар өчен.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«2025 елның 31 октябрендәге 1нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 2025 елның 31 октябрендәге 2 нче номерлы «2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Кәкре Елга торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында» карарларынын текстны бәян итеп, үзгәрешләр кертергә ризамы?
«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәкре Елга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан,1 нче торкем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда 750 сум күләмендэ. бер тапкыр бирелә торган түләүне, 2 төркем инвалидларга 375 сум күләмендә билгеләп, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп киметеп, үзара салым кертүгә ризамы?»;
түбәндәге редакциядә:
«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәкре Елга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан,1 нче торкем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда 750 сум күләмендэ. бер тапкыр бирелә торган түләүне, 2 төркем инвалидларга 375 сум күләмендә билгеләп, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп киметеп, үзара салым кертүгә ризамы?»

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
- 2025 елның 21 ноябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә: Кәкре Елга авылы, Совет ур., 22 йорт;
- Кәкре Елга торак пунктында сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
-Кәкре Елга торак пункты халкына гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.
4. Әлеге карарны Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, кабул ителгән көннән алып 10

көн эчендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) тиеш.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Кәкре Елга авыл
җирлеге башлыгы
Азнакай муниципаль
районы башлыгы




И.М.Мөхәмәтҗанов